Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30.01.2025

Менделеевск ш.

№65

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
мәетне җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Мәетне җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 9165 сум 37 тиен күләмендә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә расларга һәм гамәлгә кертергә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәетне җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварендагы 46 номерлы карары 2025 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 30 гыйнварендагы
65 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
мәетне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
(табутта күмү)

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3087,59 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1306,20 |
| 4. Кабер казу һәм күмү) | 4771,58 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 30 гыйнварендагы
65 номерлы карарына 2 кушымта

2025 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
Мәетне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
(кәфенләү)

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 160,92 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм илтеп җиткерү | 2926,67 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1306,20 |
| 5. Кабер казу һәм күмү) | 4771,58 |
| Барлыгы | 9165,37 |